ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2022 г. Заинск № 559

**Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәмнең өстәмә чаралары турында**

Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы затларның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү максатында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй шәһәре һәм Зәй районы хәрби комиссариаты тарафыннан мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләренә түбәндәге өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:

1.1. Балаларга Зәй муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча шөгыльләргә бушлай йөрү (түгәрәкләр, секцияләр һәм башка шундый шөгыльләр) мөмкинлеге.

1.2. Балаларга Зәй муниципаль районы муниципаль учреждениеләре уздыра торган белем бирү-танып белү, мәдәни-күңел ачу, спорт-савыктыру чараларына бушлай керү мөмкинлеге.

1.3. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» муниципаль казна учреждениесе буйсынуындагы муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрдән балаларның түләүсез файдалануы.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының

www.zainsk.tatar.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән законлы көченә керә һәм 2022 елның 21 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.М. Архипова**

Сычева Ю.А.,
Журавлева Ю.С.
8(85558) 7-10-27